**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» сентябрь 2018 ел** **№ 90**

**2018 нче елның 29 нчы мартындагы 78 нче номерлы Совет Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләүне камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2017 нче елның 5 нче декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актларының) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2017 нче елның 5 нче декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Уставы нигезендә, авыл җирлеге советы, Красносельский авыл җирлеге Советы

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турында 2018 елның 29 мартындагы 78 номерлы Красносельский авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2.1 пунктының 11 нче пунктчасын төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 3.2.1 пунктына 15 нче пунктчасы өстәргә;

«15) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итү;»;

3) 4.2 пунктындагы 1 нче пунктчаны төшереп калдырырга;

4) 4.7 пунктындагы 2, 3 нче пунктчаларны төшереп калдырырга;

5) 4.9 пунктындагы 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) гражданнар оборонасы өлкәсендә халык әзерләүне оештыралар;»;

6) 4.9 пунктындагы 4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) гражданнар оборонасы идарәсенең техник системасын, хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү системасын, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр, саклау корылмаларын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын кулланугa даими әзерлек хәлендә төзиләр һәм ярдәм итәләр;»;

7) 4.9 пунктындагы 8 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8) халыкка үз вакытында хәбәр итүне, шул исәптән халыкка ашыгыч хәбәр итүне, хәрби конфликтларда яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында хәбәр итүне тәэмин итәләр;»;

8) 4.9 пунктындагы 9 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерли һәм карап тора, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерли;»;

9) 4.11 пунктындагы 3 нче пунктчасын «төшереп калдырырга»

2. Әлеге карар Интернет челтәрендә веб-адрес буенча Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылып халыкка җиткерелергә тиеш.

Совета Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Кәлимуллин